КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2019 ел, 15 апрель | г.Казань | № 290

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 15 август, 671 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 15 август, 671 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

V бүлекнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары тренерының вазыйфаи оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \sum_{i=1}^{n} N_i,$$

монда:

$O_d$ – физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары тренерының вазыйфаи окладлары;

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган физик культура хезмәткәрләренең база оклады күләме;

$N_i$ – әлеге Нигезләмәнең IV бүлеге нигезендә кабул ителә торган физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары тренеры хезмәтенә бер шөгыльләнүче өчен түләү нормативлары.»;

VI бүлектә:

1 пунктның 1.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр.»;

8.12 пунктчасы 9 пункт дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10. Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр урта, әйдәүче звено һәм җитәкче составка керә торган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган мәдәният хезмәткәрләренә, икенче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган физик культура хезмәткәрләренә, урта медицина һәм фармацевтика персоналының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган медицина хезмәткәрләренә, табиблар һәм провизорларның һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган медицина хезмәткәрләренә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{it} = O_d \times D_{it},$$

монда:

$B_{it}$ – хезмәт интенсивлыгы өчен түләү;

$O_d$ – физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладу;

$D_{it}$ – хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләү күләме.

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләме әлеге Нигезләмәнең 6 нчы таблицасында китерелгән.»;

VIII бүлеккә түбәндәге эчтәлекле яңа $8^1$ пункт өстәргә:

«$8^1$. Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр физик культура һәм спорт дәүләт оешмасы җитәкчесенә (җитәкчесе урынбасарларына, баш хисапчысына) билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{it} = O_d \times D_{it},$$

монда:

$B_{it}$ – хезмәт интенсивлыгы өчен түләү;

$O_d$ – физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары җитәкчесенең (җитәкчесе урынбасары, баш хисапчы) вазыйфаи окладу;

$D_{it}$ – хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләү күләме.

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләме әлеге Нигезләмәнең 6 нчы таблицасында китерелгән.»;

Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә кушымтасын түбәндәге эчтәлекле 6 нчы таблица өстәргә:

Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымтага түбәндәге эчтәлекле 6 таблица өстәргә:

«6 таблица

Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләме

| Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары исеме | Һөнәри-квалификация төркемнәренең, вазыйфаларның исеме | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| «Спорт сарае» дәүләт бюджет учреждениесе | оешма җитәкчесе, оешма җитәкчесе урынбасарлары, баш хисапчы | 50,0 |
| | урта, әйдәп баручы звеноның һәм җитәкчелек составының мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган мәдәният хезмәткәрләре | 50,0 |
| | икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган физик культура хезмәткәрләре | 50,0 |
| | урта медицина һәм фармацевтика персоналының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган медицина хезмәткәрләре | 50,0 |
| | табиблар һәм провизорлар | 50,0»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак һөнәрләренең эшче, мәдәният эшчесе, сәнгать һәм кинематография һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

IV бүлектә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр.»;

түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6. Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр эшче, мәдәният эшчесе, сәнгать һәм кинематография гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре, Татарстан Республикасы физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларының хезмәткәрләренә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{it} = O_d \times D_{it},$$

монда:

$B_{it}$ – хезмәт интенсивлыгы өчен түләү;

$O_d$ –Татарстан Республикасы физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең гомумтармак һөнәрләренең эшче, мәдәният эшчесе, сәнгать һәм кинематография гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре вазыйфаи оклады;

$D_{it}$ – хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләү күләме.

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләме әлеге Нигезләмәнең 2 таблицасында китерелгән.»;

Татарстан Республикасы физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең гомумтармак һөнәрләренең эшче, эшче мәдәният, сәнгать һәм кинематография һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымтада:

кызыксындыру характерындагы түләү бирелә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Берлеге, Совет Социалистик Республикалар Берлеге составында һәм автоном республикалар дәүләт бүләкләре исемлеген 1 таблица дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле 2 таблица өстәргә:

«2 таблица

Татарстан Республикасы физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең гомумтармак һөнәрләренең эшче, эшче мәдәният, сәнгать һәм кинематография һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләме

| Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт дәүләт оешмалары исеме | Һөнәри-квалификация төркемнәренең исеме | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Спорт сарае» дәүләт бюджет учреждениесе | җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре | 50,0 |
| | эшче мәдәният, сәнгать һәм кинематография профессиональ квалификация төркемнәре | 50,0 |
| | эшче һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре, «сакчы (вахтер)», «хезмәт һәм житештерү бүлмәләрен җыештыручы», «тракторчы», «урам җыештыручы», «территорияне җыештыручы» вазыйфаларыннан тыш | 50,0». |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин